**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «4» сентябреннән № 60-458

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 26 маендагы 34-270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 26 маендагы 34-270 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2024 елның 27 декабрендәге 51-393 номерлы карары редакциясендә) (алга таба – Нигезләмә) расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 7 бүлегенең 7.1. пунктындагы 20 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) мәгълүмат эшкәртүне һәм (яисә) саклауны тәэмин итә торган җиһазлар урнаштыру өчен проектланган һәм файдаланыла торган инженерлык-техник тәэмин итү системалары комплексын (белешмәләрне эшкәртү үзәкләре) үз эченә алган бердәм билгеләнештәге биналар, бина өлешләре яисә бүлмәләр җыелмасы;».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә

муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы урынбасары

Н.И. Попкова